# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 13 (689) 12 июль 2019 ел (1440, Зөлкагъдә) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Яхшы киңәш - җан азыгы



Саулык-сәламәтлек кадәр кыйммәтле вә ләззәтле нәрсә һич юктыр. Моны исә сәламәт вакытыгызда белегез. Ятимнәр хакларына кул сузмагыз, күршеләр белән яхшы көн кичерегез. Намазларыгызны калдырмагыз, мөмкин булганда мәчеткә барыгыз, бер-берегезнең хәлен белешеп торыгыз, изгелек белән яшәгез. Усаллыктан бер-берегезне тыегыз. Гакылсызлар белән дус булмагыз, яхшы мөэмин булырга теләсәгез, Аллаһы Тәгалә юлына берләшегез, базарларда кирәксезгә җыелып сөйләшеп утырмагыз, халык җомга намазына барганда, сез сәфәргә чыгып китмәгез. Юк-бар нәрсә өчен ачуланмагыз, кешеләрнең өстенлек вә бәхетләренә һич вакытта көнләшмәгез, көнләшү фәкать вөҗданны рәхәтсез итеп тору булып, башка бер файдасы юктыр. Үлем килүеннән хәбәрсез булып тормагыз, һәрвакыт вә һәр сәгатьтә исә үлем килү мөмкиндер, Аллаһы Тәгаләгә якын итәчәк нәрсәләрнең ахирәттә уттан ерак итәчәген, утка якын иткән нәрсәләрнең Аллаһы Тәгаләдән ерак итәчәген һәрвакыт күңелегездә тотыгыз!

**(Риза Фәхреддин. «Әхлак гыйлеме».**

Фото интернеттан алынды)

## Сабантуйлар дәвам итә




Лаеш районының Сингел авылында беренче тапкыр мөселман Сабантуе узды. Татарстан мөхтәсибәтләрендә мөселман Сабантуйлары даими уздырыла, бу юлы Сингел авылында мөселманча Сабантуйны элекке тотқыннарны тернәкләндерү һәм адаптацияләү үзәге генераль директоры Азат Гайнетдинов оештырды. Сабантуйның хөрмәтле кунагы булып Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин килде. Моннан тыш, 2019 елның 14 июлендә Балтач районының Борбаш авылында XII Республикакүләм мөселман балалар Сабантуе узачак. Чараның төп оештыручысы – Балтач районы имам-мөхтәсибе, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев.

## Тиздән - Корбан гаете

Татарстан республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтендә Казыйлар шурасының киңәйтелгән җыелышы үтте. Утырышта барлык төбәк казыйлары, мөфтиятнең җитәкчелек вәкилләре катнашты. Игътибар үзәгендә төп мәсьәлә буларак Корбан бәйрәменең гает намазы вакытын һәм корбан нисабын билгеләү торды. Корбан гаете 11 августта булачак. Корбан нисабының күләме дә тәгаенләнде: барлык чыгымнардан һәм әҗәтләрдән тыш 20 мең сум акчасы булган кешегә корбан чалу мәҗбүри санала. Бәйрәм намазы Казанда 4.30 сәгатьтә укылачак. Бәйрәм вәгазен иртәнге 4 тә башлау тәкъдим ителә. Башка шәһәр-авылларда гает намазы һәм вәгазе вакыты кояш чыгу вакытына карап билгеләнәчәк. Элекке еллардагы матур гадәт буенча, балалар өчен бәйрәм чаралары мәчет каршындагы мәйданчыкларда, район-шәһәр паркларында дәвам итәчәк. Алар гает көннәрендә уздырылачак.

## ТР МДН хәбәр итә



Казанның Зур Клыки бистәсендә “Сәлах” мәчете ачылу тантанасы узды. Әлеге чарада дин әһелләре, иганәчеләр, җитәкчеләр катнашты. Коръән аятьләрен мәчетнең имамы Тимергали хәзрәт Юлдашев укыды һәм дога кылды. Мәчет ачылу шатлыгы белән уртаклашырга килүчеләр алдында вәгазь-нәсыйхәт сүзләре белән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясады. “Сәлах” мәчете Казанның Мамадыш тракты, 18 йорт адресы буенча урнашкан.

***

Аксубай районының Яңа Ибрай авылында 2 нче мәхәллә мәчетенең 25 еллыгын билгеләп үттеләр. Тантаналы чарада Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча киңәшчесе Равил хәзрәт Зөфәров, Аксубай муниципаль районы башлыгы Камил Гыйльманов, күрше авыл һәм шәһәр имамнары, авыл халкы һәм башка күпсанлы кунаклар катнашты. Тантаналы чарадан соң Аксубай районы имамнары җыелышы узды.

***



Чаллыда, “Хәләл үзәк”тә чираттагы хәләл ярминкә узды. Сатуда катнашучылар бары тик үзләре әзерләгән натураль ризыклар гына тәкъдим итте. Балык, ит, глютенсыз ипи, чүпрәсез пешкән камыр ризыклары барча сатып алучылар тарафыннан югары бәяләнде. Сатучылар да, сатып алучылар да бик канәгать калдылар.

***

Карабаш бистәсе үзәк мәчетендә Бөгелмә шәһәре һәм Бөгелмә районы мөхтәсибәте тарафыннан оештырылган имамнар җыелышы булып узды. Чарада Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр (җирлекләр) белән эшләү буенча киңәшчесе Равил хәзрәт Зөфәров, Бөгелмә районы имам-мөхтәсибе Рамил хәзрәт Хөснетдинов, шәһәр һәм район имамнары катнашты. Егерме имамга дини эшчәнлек алып бару хокукы бирүче төп документ – шәһадәтнамәләр тапшырылды.

# Без кем?

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые.**

Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримдә («Тин» сүрәсе, 4 нче аять): «Без адәм баласын күркәм сурәттә халикъ кылдык», — ди. Кызганыч, без еш кына кешелек сыйфатларыбызны югалтабыз. Кемгә генә булса да: «Без кемнәр?» — дигән сорауны куйсаң, горурланып: «Без — кешеләр», — дип җавап бирә. Берәр кешегә ачуыбыз чыкса, без аңа нәрсә диеп кычкырабыз? Әйе, бик дөрес: «Хайван», — дибез. Кешене хайваннан аера торган бик күп сыйфатлар бар. Бүген шуларның берничәсен әйтеп үтмәкче булам. Мин санап китәргә теләгән әлеге сыйфатларны Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): «Кешене бизи торган дүрт җәүһәр», — дип атады. Бар кеше дә үзен мөэмин-мөселман дип санамаска мөмкин. Әмма бар кеше дә үзен кеше дип саный, шуның өчен дә шушы дүрт сыйфатка тукталырга булдым.

Кеше хайваннан аера торган беренче сыйфат — акыл. Хайваннарда күпмедер акыл булса да, ул кешедәге кебек камил дәрәҗәдә түгел. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә кешеләргә мөрәҗәгать иткәндә, күп урыннарда: «Йәә үлил әлбәәәбе», ягъни: «Әй, акыл ияләре», — ди. Адәм баласы акылы ярдәмендә өй хәтле филләрне дә, кечкенә генә бал кортын да үзенә хезмәт иттерә. Кешенең хакыйкый гүзәллеге дә акылында. Иң чибәр дип саналган кыз яисә егет акылсыз кала икән, берәү дә аңа борылып карамый.

Акылны баета, зиннәтли торган гамәл ул — гыйлем алу. Шуңа күрә Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): «Бишектән алып ләхеткә кадәр белем алу фарыз», — ди. Акыл, үз чиратында, безнең өскә бу¬рыч та йөкли. Акылның зәкяте — намаз. Акыллы кеше, авырумы ул, шатлыктамы ул, кайгыдамы ул, мәшәкатьтәме ул, баймы ул, ярлы¬мы ул, намаз укырга тиеш. Намаз укымаса, ул акылының хакын түләмәгән була, Аллаһның биргән нигъмәтләренә шөкерана кылмау¬чы була. Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримдә («Ибраһим» сүрәсе, 7нче аять): «Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтемне сезгә арттырырмын, әгәр көферлек кылсагыз, газабым каты», — дип кисәтте. Бүген югары уку йортларын тәмамлаучыларның күбесе хәтта аракының хәрам икәнен төшенә алмый икән, бу инде намаздан башка файдалы белем була алмаганын күрсәтә. Тормышта акылны чыгара торган әйберләр дә бар. Шу¬ның иң беренчесе — ачу. Ә ачуны тыеп тора алу сәләте, аны тышка чыгармау — акыллылык билгесе. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.)нең бу турыда бик күп хәдисләре бар. Менә кайберләре: «Кыз¬ма», «Ачуың чыкса, дәшми тор», «Таулар-ташлар күчерүче, ярышлар¬да җиңүче батыр батыр түгел, ачуын тышка чыгармаучы — батыр». Ачу гадәттә күңел тынычсызлыгыннан, күңелдә тәртип булмау¬дан килә. Күңелне ничек тынычландырып була соң? Аллаһ Раббы¬быз Коръәни Кәримдә («Рәгыд» сүрәсе, 28нче аять): «Күңелләр Аллаһның зикере илә тынычланырлар», — ди. Ачуың чыкса, утырып тор, күзләреңне йом, борын аркылы әкрен генә тирән сулыш ал да, берничә мәртәбә: «Ләәә иләәһә илләллааah», — диген, сулышыңны чыгар. Шул рәвешчә 10-15 минут кабатла. Алай да үтмәсә, ятып тор. Ярдәме тимәсә, тәһарәт ал, мөмкинлегең булса, госел коен. Ачу шайтаннан, шайтан уттан яралтылган, ә ут судан курка. Намаз укы, Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримдә («Гәнкәбут» сүрәсе, 45нче аять): «Намаз бозык, фәхеш эшләрдән саклый һәм ул зикерләрнең иң олысы», — ди. Димәк, күңелне тынычландыра, чистарта торган иң яхшы дару намаз икән. Намаз укымаганга күрә бүген күп кеше төрле стресслардан җәфалана.

Пәйгамбәребез с.г.в. белән Әбү Бәкер (р.г.) сөйләшеп утыралар икән, бер кяфер килеп, Әбү Бәкер (р.г.)не төрле сүзләр әйтеп мыскыллый башлый. Күпмедер вакыттан соң Әбү Бәкер (р.г.) җавап кайтара башлауга, Пәйгамбәребез (с.г.в.) аны туктата: «Дәшмә», — ди. Әбү Бәкер (р.г.) гаҗәпләнеп: «Ул миңа никадәр сүз әйтте, аны туктатмадың, мине беренче сүздән үк туктатасың», — дигән. Расүлебез (с.г.в.): «Ул сине сүккәндә, аның артында шайтан иде, синең артта фәрештә торды, син җавап кайтара башлау белән, шайтан синең артыңа күчте, сине шайтан коткысында калдырасым килмәде», — дигән. Ачу ут кебек, өстәмәсәң, ут та сүнә, ачуны да дәшми торып кына сүрелдереп, туктатып була, югыйсә, зур низаглар, үпкәләшүләр, хәтта сугыш та килеп чыгарга мөмкин.

Акылны ала торган икенче әйбер: ул — хәмер. Шуңа күрә халыкта хәмер эчүне: «Тилелекне кыйбат бәягә сатып алу», — дип йөртәләр. Хәмер эчүче өчләтә гөнаһлы. Беренчедән, Аллаһ хәрам иткән әйбердән тыелмый, икенчедән, Аллаһ әманәт итеп биргән акылын сакламый, шуның нәтиҗәсендә бик күп бәла-каза, борчу-мәшәкатьләр ясый, үзенә дә, тирә-юньдәгеләргә дә. Өченчедән, байлыгын кирәкмәгән җиргә сарыф итә.

Хәмер алган акчасын гаиләсенә, ятимнәргә, мохтаҗларга бирсә, ничек күркәм булыр иде. Бүген: «Гәзит-журналларга язылырга, китап алырга, утка, газга түләргә акчам юк», — дигән кешеләр аракы өчен меңнәрчә сум акча сарыф итәләр, унар мең сумлык аракы алып туйлар үткәрәләр. Менә акылсызлыкның ачык мисалы.

Акылны ала торган өченче әйбер — телевизор. Күзгә кирәгеннән артык йөк йөкләү акылга зыян китерә икән. Бүген көн-төн телевизор карау, компьютерда төрле уеннар уйнап утыру файдага түгел. Акылга җиңеләючеләр, үз-үзенә кул салучыларның саны көннән-көн арта бару — менә моның ачык дәлиле.

Кешене кеше итә торган икенче сыйфат — дин. Хайваннарда дин юк. Кеше динсез яши алмый. Кайберәүләр: «Без яшибез бит әле», — дип әйтергә мөмкин. Әмма бу — ялгыш фикер. Нәрсә ул дин? Ул: «Юл», дигән сүз. Нинди юл? Аллаһның барлыгын, берлеген танып, Аның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәү юлы. Аллаһны тану ул: «Ләә иләәһә илләллааah», ягъни: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга, табынырга лаеклы һич¬бер илаһ юк», — дип раслау. Бүген: «Динсез яшим», — дигәннәрнең табына торган илаһлары юкмыни? Әлбәттә, бар. Кайсыныкы акча, кайсыныкы хәмер, кайсыныкы наркотик, кайсыныкы хатын-кыз һ.б. Димәк, һәркемнең дине бар, әмма берәүләрнеке хак, берәүләрнеке батыйль. Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримдә («Гыймран» сүрәсе, 19нчы аять): «Минем каршымда иң күркәм дин — Ислам дине», — ди. Әле Җир йөзендә Исламнан башка бер генә диннең дә кешелек дөньясын хәмер эчү, отыш уеннары уйнау һ.б. яман күренешләрдән азат итә алганы юк. Чын Ислам кануннары буенча яшәгән илләрдә әлеге афәтләр юк. Мөселманнар: «Намазсыз яшәүнең мәгънәсе юк», - дисәләр, «Мин динсез», — диючеләр: «Аракыдан башка күңелле итеп яшәп булмый», — диләр. Димәк, аларның илаһлары аракы, гыйбадәтләре исерткеч эчеп тилерү, «саваплары» хәмергә акча түгү, шул тилелекне «шат¬лык» дип кабул итү. Эчүнең үзенең ритуаллары эшләнгән. Туйларда, юбилейларда, бәйрәмнәрдә теләк теләгәндә, кеше кулында аракы булырга тиеш, дип кабул итә. «Аракы эчми яшәп булмый», — дип уйлау — кешелек дөньясын һәлакәткә алып бара торган иң яман юл. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): «Аракы эчү — потка табыну белән бер», — диде. Әгәр кешедә «акыл» дигән сыйфат булса, ул хакны батыйльдән аера белергә тиеш. Хак диннән чыгара торган сыйфат та бар кешедә. Ул — көнчелек. Атабыз Адәм яралтылгач, уң ягында бик күркәм бер затны күргән дә сораган: «Син кем?» Әлеге зат: «Мин — иман», — дигән. «Син минем кай җиремә урнашырсың?» — дигәч, иман: «Кальбеңә», — дип җавап биргән. Сул ягына караса — бик күңелсез бер затны күргән. «Син кем?» — дигән. Әлеге зат: «Мин — дөнья», — дигән. «Син минем кай җиремә урнашырсың соң?» — дигәч, дөнья да: «Кальбеңә», — дигән. «Соң анда иман бар бит, сиңа урын юк», — ди икән Атабыз Адәм. «Кальбендә мине сөю урнашкан кешедә иманга урын калмас», — дигән дөнья. Бүген без ашыгабыз, дөнья куабыз. Намаз укырга, дини белем алырга вакытыбыз юк. Ашарга юкмы безнең, кияргә юкмы, торырга өй юкмы? Барысы да бар, тик канәгатьлек юк, чөнки кемнекедер ми¬некеннән күбрәк, артыграк. Көнчелегебездән без кешедә булган бай¬лыкка чыдый алмыйбыз. Кемнәндер узарга, кемнәндер арттырырга тырышып бәргәләнәбез, кабаланабыз. Кая ашыгабыз?! Әлбәттә, ка¬бергә. Акыллы кеше мәңгелек йортын кайгырта. Әмма көнчелек без¬не, кешедә булган дөнья зиннәтләренә кызыктырып, Аллаһ кушкан¬нарны үтәргә вакытыбызны калдырмый, хәрамга этәрә, шулай итеп, безне хак диннән яздыра. Көнчелекне җиңәр өчен үлемне еш искә алырга, җеназаларда кат¬нашырга, искә алу табыннарына барырга кирәк. Кем иде, кая китте, үзе белән нәрсәләр алып китте, кемнәргә нинди тәрбия биреп китте? Күңелеңне Аллаһның зикере белән никадәр күбрәк тутырсаң, дөньяны уйларга урын әзрәк калыр.

Кешене кеше иткән өченче сыйфат — оят. Кеше булган кеше ояла белә. Хайваннарда оят дигән хис юк. Ке¬шеләр ояла белергә, тиешле киемнән гаурәтләрен каплап йөрергә тиеш. Кызганыч, бүген бу кыйммәт тә югалып бара. Пәйгам¬бәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): «Һәр кеше оятын югалтса, тиеш¬ле җирләрен каплап йөрмәсә, зинаны ачыктан-ачык кылса, Аллаһ аларга моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән авырулар җибәрер», — дип безне кисәтте. Менә ни өчен бүген Җир йөзендә СПИД тантана итә. Иң аянычы — СПИДка каршы көрәшәбез, дип сәхнәгә шәрә кызлар чыгарып биетәләр. Әле моңарчы авырмаганнар авыр¬мыйча кала күрмәсен, дигән кебек була. Телевизордан зинаны ничек итеп кенә күрсәтмиләр. 70тән узган әбиләребез телевизор төбендә ашый-ашый шуны карап утыра. Алай утыру да бозыклыкка катнашу һәм аны тарату шикелле үк гөнаһ. Әгәр чын-чынлап СПИДка каршы көрәшик, дибез икән, оят төшенчәсен алга куеп, тәртипле итеп яши башларга кирәк. Оятны бетерә торган сыйфат — нәфес. Нәфесебез без¬не төрле яктан ләззәтләргә кызыктырып, оят хисләрен юкка чыгара. Оялу хисен булдыру өчен нәфесне җиңәргә кирәк. Нәфес ул безне үлемгә дә алып бара. Авыруларның күбесе безгә нәфесне җиңә алмаганга күрә килә. Без күп вакыт, ләззәт алабыз дип, авыру алабыз. Берәү күп ашаудан, берәү кайнар ашаудан, берәүләр майлы-баллы, тозлы ашаудан, хәмер эчүдән яки тәмәке тартудан, берәүләр шәрә йөрүдән, кайберәүләр зина кылып йөрүдән ләззәт ала. Дин ягыннан булган чикләүләрне үзенең рәхәт, күңелле тормышын чикләү дип кабул итә. Югыйсә, нәфеснең һәр ләзәте артында төрле авыру-мәшәкать, димәк, үлем тора. Акыллы кеше нәфесен чикли белергә, димәк, күп авыруларга киртә куя белергә тиеш. Авырып китсәк, үзебезгә аерым бер игътибар таләп итәбез. Лаекмы без аңа? Без бит нәфес колы булып үз тәнебез каршында җинаять эшләдек. Нәтиҗәдә, Аллаһ биргән сәламәтлек китте, чир килде. Гаеп күп вакыт үзебездә. Нәфес үзе ике канатлы. Бер канаты — йокы, берсе — ашау. Димәк, ул бик каты күтәрелмсен дисәк, бер канатын булса да зәгыйфьләндерү кирәк. Ашау дигән канатын җиңәр өчен Аллаһ Раббыбыз безгә уразаны фарыз кылган. Бер ай ураза гына җитмәсә, Пәйгамбәребез (с.г.в.) хуплаган нәфелләре дә бар: ай туган вакытта өч көн, дүшәмбе-пәнҗешәмбе көннәр, Рәҗәб, Шәгъбан, Мөхәррәм айларында, Гарәфә көне һ.б. Һәркемнең дә нәфел уразаларын тотарга көче җитмәскә мөмкин. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): «Әгәр бер урынга мөселманнар җыелса, анда Аллаһ турында фикер йөртелсә, бер сәгать андый гыйлем алу 7 көн нәфел уразадан саваплырак», — диде. Ни өчен җомга намазы фарыз, ике гаеттән олы? Чөнки җомгада вәгазь булмаса, җомгадан китми, гаеттә вәгазь сөйләнмәсә, гаеттән китә. Җомга намазларына йөрү, вәгазь кичәләренә йөрү, дини гыйлем алу да нәфесне җиңәргә булыша икән. Нәфеснең икенче канаты — йокы. Менә ни өчен иртәнге намазның, тәхәҗҗүд намазларының савабы искиткеч күп. Без бу очракларда йокыны чиклибез, аны җиңәбез. Димәк, нәфесне дә җиңәбез. Дини гыйлем алуның да максаты — нәфесне җиңәргә өйрәнү. Фарызларны үтәп тә нәфесеңне йөгәнли алмагансың икән, нәфелләреңне арттыр. Нәфес безнең белән түгел, без нәфес белән идарә итәргә тиеш. Бүгенге бозык җәмгыятьтә яшәп тә, үзебездә шул бозыклыкларга кушылмаска көч таба алсак, гаять дәрәҗәдә саваплы булырбыз. Са¬ваплы булам, дип каядыр чыгып качарга омтылу дөрес түгел. Без шушы халык эчендә яшәргә, күркәм мисалларыбыз, үрнәкләребез белән тәрбия эше алып барырга тиеш.

Кешене кеше иткән дүртенче сыйфат — изге гамәлләр. Нәрсә ул изге гамәлләр? Намаз уку, ураза тоту, мәчеткә йөрү... Әмма әле бу изге гамәлләр үзең өчен генә тырышу. Дөньядан күпмедер өлешләндең: өең, машинаң, мал-туарың, хатының, балаларың бар. Хәзер инде ахирәтне дә онытмыйсың, җәннәтне кәсеп итәсең. Бу да мактауга лаек, чөнки аларны үтәмәсәң зур гөнаһлы буласың, Аллаһның ризалыгын ала алмыйсың. Аллаһ Раббыбыз: “Мин мохтаҗлар, авыру-сырхаулар, моңлы-зарлылар янында булам, Миңа якын буласыгыз килсә, аларга якын булыгыз,” – диде. Авыруларның хәлен белсәң, ятим-мохтаҗларга ярдәм итсәң, кайгылыларның кайгыларын уртаклашсаң – бу үзеңне генә кайгырту түгел, башкаларга да ярдәм итү, чын изге гамәлләр кылу була. Пәйгамбәребез с.г.в.: “Сәдаканы үзеңнән, гаиләңнән башла”, - диде. Хатының белән тату яшәү, балаларыңны кайгырту, аларга дини тәрбия бирү, ата-ананы хөрмәтләү – аеруча әһәмиятле. Шуның өчен кешеләр әти-әниләрен хөрмәтли, тәрбияли, инвалидларга, ятимнәргә, мохтаҗларга, авыруларга ярдәм итә. Хайваннарда мондый хисләр юк. Бүген бездә дә бу хисләр югалып бара икән, димәк, без хайванга әйләнеп барабыз.

Бер мулла мәчеттә вәгазь сөйли икән: “Мохтаҗларга, ятимнәргә, мескеннәргә әз генә булса да сәдака биреп, Аллаһка якынаегыз. Сәдака күккә ашар, бәла-каза күктән иңәр, күктән иңгән бәла-казаларга сәдака киртә булып торыр. Ләкин шайтан сезгә бу изге эшне эшләргә комачаулар”.

Бер урта хәлле кеше җомгадан кайткач, авыл башындагы ярлырак кешегә ярма илтеп кайтырга була, пакетка бераз ярма тутырып өеннән чыгып барганда, хатыны, юлына төшеп: “Үзебезнең ашарга җитәр-җитмәс, син монда тагы изгегә салынып кешегә ярма ташып йөрисен, керт, кире бушат!” - ди. Ире тавыштан гарык булып ярманы кире кертеп бушата.

Икенче җомгада хәзрәт янына килеп: “Хәзрәт, сүзең дөрес булды, миңа ана шайтан үзе очрап, изге гамәл кылырга ирек бирмәде”, - ди.

Кызганыч, без бүген күбрәк начар кешеләр, җинаятьчеләр турында сөйлибез. Яхшы кешеләр, яхшылыклар гел читтә кала. Изге гамәл кылучыларны матур итеп күрсәтә белү, гәрчә алар үзләре моны теләмәсә дә — ул яхшылыкны тарату, күбәйтү булып тора. Изге гамәлләрне юкка чыгара торган әйбер — гайбәт. Берәү икенчесенең гайбәтен сөйләсә, гөнаһ эшләп кенә калмый, ул кешенең гөнаһысын да үзенә ала, үзенең савабын ул кешегә бирә. Акчаны табу гына аз, аны дөрес итеп тота белергә кирәк булган кебек, изге гамәлләрне дә кылу гына аз, саклый белергә дә кирәк. Изге гамәлләрне саклау ул — телеңне гайбәттән саклау. Пәйгамбәребез с.г.в.: “Сезнең телегез сезне борыныгыздан өстерәп җәһәннәмгә алып керер,” – диде.

Бу дөньяга кеше булып туганбыз, кеше исемен йөртәбез икән, кешелек сыйфатларыбызны югалтмыйча яшәргә Аллаһ Раббыбыз барыбызга да насыйп кылса иде.

## БЕЛӘСЕЗМЕ?

Тәүлек эчендә намаз кылынмый торган вакыт аралары бар:
- кояш чыккан вакытта;
- зәвәл вакытында;
- кояш батканда.

Искәрмә: иртәнге намазның вакыты кергәч, шул намазның сөннәте белән фарызыннан кала бүтән намаз укымыйлар. Шулай ук икенде намазының фарызыннан соң нәфел намазлары укылмый. Кояш баеган вакытта бары тик шул көннең икенде намазын гына кылырга ярый, әгәр дә ул укылмаган булса.

**(“Ислам дине нигезләре”ннән.)**

ӘДӘБИ СҮЗ

## Соңгы сынау өркетә

*Туры гына салынмаган –*
*Барган юлым ураудыр.*
*Җирдә яшәү кеше өчен*
*Сынау арты сынаудыр.*
*Күп сыналдым, инде җиткән*
*Картлыгыма барганда.*
*Шулай дим дә, тыныч кына*
*Яшәп булмый һаман да.*
*Килеп чыга тормышымда*
*Сынауның иң яңасы.*
*Ахры, соңгы сулышкача*
*Бу җирдә сыналасы.*
*Үтәрменме, юкмы димен –*
*Соңгы сынау өркетә.*
*Бакый дөньяга күчкәчтен*
*Сират күпере көтә.*

***

*Яхшы кеше әллә каян ул сизелә.*
*Андыйның шул күзләреннән нур сибелә.*
*Итагатьле, тыйнак,*
*сабыр, мәрхәмәтле –*
*Шундый кеше янда булса, җан сөенә.*

***

*Караңгыны җиңә ала тик яктылык.*
*Күңелеңне билән алсын ихласлык.*
*Игелекле гамәлләрдә кит ачылып,*
*Кешеләргә зыян салма, ит яхшылык!*

***

*Кешеләргә булсак иде игътибарлы.*
*Шуңа өстәп ихлас җанлы, миһербанлы.*
*Игелекле гамәлләрне күбрәк кылып*
*Яуласаңчы иде, дустым, ихтирамны!*

**Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ,**
**Актаныш районы**
**Тат.Суыксу авылы.**

## Тугры юл

*(Төрекчәдән Фатих Кутлу тәрҗемәсе)*

***Табигыйн имамнарының әфәндесе Малик ибне Динар хәзрәтләре тугры юлга басу тарихын үзе сөйли:***

Тирә-юнемдәгеләр, кылган золымнарым, явызлыкларым аркасында миннән читләшкәннәр иде. Бервакыт, гаилә корып, әти булуы теләге күңелемә килде. Өйләндем һәм бер кызым булды. Исемен Фатыйма куштым. Аны бик нык яраттым. Ул үскән саен күңелемдәге иман да үсте һәм эчемдәге гыйсъян уты сүрелде. Беркөнне кулымда аракы шешәсе бар иде. Әчәргә җыенганда Фатыйма аны кулы белән аударды. Әле ике яшь тә түгел иде үзенә. Әйтерсең, болай эшләргә Аллаһ кушты. Ул үскән саен күңелемдәге иман да балкыды. Шушы хәл Фатыйма өч яшен тутырганчы дәвам итте. Күп тә үтмәде, бәгырь җимешем Фатыйма арабыздан китте. Кызым үлгәч, хәлем элеккедән дә начаррак булды. Миндә тирә-ягымда булган мөселманнардагы сабырлык юк иде. Түбәнгә тәгәрәп китә башладым. Шайтан бертуктаусыз мине котырта иде. Һәм көннәрнең берсендә ул миңа килеп: “Белсәң иде бүген нихәтле исерәчәгеңне. Гомереңдә дә шулай шәп исергәнең булмады, күр дә тор!”- диде һәм мин ул төнне бик теләп эчеп исерергә булдым. Шуннан төне буе, таң атканчы эчтем дә эчтем! Әллә нинди төшләр күрә-күрә интегеп беттем. Ә соңгы күргән төшем бөтенләй котымны алды минем. Кыямәт көне җиткән! Кояш каралган, диңгезләр утка әверелгән. Бертуктаусыз җир тетрәүләре булып тора. Бөтен кешеләр мәхшәр мәйданында төркем-төркем җыелганнар. Мин дә шул кешеләр арасында. Тавышлар ишетелә, берәү дәшә: «И, фәлән улы фәлән! Җаббар янына, сорау алырга барабыз, әйдә!» - ди. Һәм ул минутта шул чакырылган кешенең бите куркуыннан кап-кара була. Бик күп кеше чакырылды. Ниһаять, чират миңа да җитте: «Әйдә Җаббар янына, соравың алыначак!» Як-ягыма карансам, берәү дә калмаган. Мәхшәр мәйданы бупбуш. Кинәт каршымда бер тычкан пәйда булды - бик зур гәүдәле, шундый ерткыч, кешегә ташланам дип тора торган. Авызын ачкан килеш миңа таба йөгерә. Мин үтә куркудан дәһшәттән кача башладым. Качып барганда, каршымда шундый карт, зәгыйфь, көчсез бер кеше пәйда булды һәм аңа җан ачысы белән: “Ahh! Мине шушы дәү тычканнан коткар!! - дидем. Ул кеше миңа: “Улым, мин бик зәгыйфь. Сине аның кулыннан коткарырлык көчем юк. Ләкин шул якка таба чап син, иншаллаһ котылырсың”. Мин дә ул күрсәткән якка таба йөгерә башладым. Дәү тычкан һаман артымнан чаба иде. Беравык каршымда җәһәннәм утын күрдем. Куркыныч дәрәҗәдәге эсселеге битемә бәрә иде! Тычкан белән җәһәннәм арасында кысылып калдым. Үзалдыма: “Мин шушы тычканнан утка керер өчен качаммы соң!?”- дидем һәм йөгерә-йөгерә, миңа шушы юлны күрсәткән теге кеше янына бара башладым. Тычкан һаман минем арттан куа иде. Теге карт кешегә: “Аллаһ хакына мине шул тычканнан коткар, ялварам сиңа!”– дидем. Ул минем хәлемне җәлләп елады да: “ Күрәсең, мин бик ябык һәм зәгыйфь. Сине коткара алырлык көчем юк. Ә хәзер шул якка чап, бу юлы, боерган булса, котылачаксың”. Шундук, ул кушкан якка таба, бар көчем белән чаба башладым. Тычкан һаман минем арттан куа, менә тешлим, менә тешлим дигәндә, каршымда бер тау пәйда булды, анда бер көтү яшь бала җыелган. Алар бер үк сүзне кабатлап кычкырып елыйлар: “И Фатыйма!! Әтиең кара! Әтиеңә карааа!”- дип. Ул вакыт теге баланың кызым Фатыйма икәнен аңладым һәм өч яшендә үлеп җәннәткә кергән кызым булуына чиксез сөендем. Чөнки ул мине дәһшәтле куркудан (тычканнан) коткарып җәннәткә кертәчәк иде. Кызым мине уң кулы белән тотып коткарды һәм сул кулы белән тычканны этеп җибәрде. Минем куркудан хәлем бөтенләй беткән иде. Нәкъ дөньяда вакыттагы кебек аны кочагыма утырттым! Ул миңа карап түбәндәге Корьән аятен укыды (Хәдид сүрәсе 16нчы аять): «Әләм йәьнилилләзинә әмәну ән тәхшәга кулубиһим ли зикриллаһ». “И иман китерүчеләр! Аллаһ зикеренә кайтыр вакытыгыз җитмәдеме?!” Мин аңа: «Кызым, сөйлә әле, ул тычкан нәрсә иде соң?!» Кызым миңа: «Ул тычкан дөньяда вакытта кылган начар гамәлләрең, гөнаһларың. Аны син үзең асрап үстердең һәм үзеңне ашарлык дәрәҗәгә син үзең җиткердең!! И әтием! Син белмисеңме әллә, дөньяда кылынган гамәлләргә ахирәттә гәүдә биреләчәген. Теге көчсез, ябык карт - синең күркәм гамәлләрең. Син аны шулай ябык, чарасыз калдырдың, үз хәлеңә елаттың. Сине коткара алмаслык дәрәҗәгә төшердең. Әгәр мин тумаган булсам һәм сабый яшьтә гөнаһсыз килеш үлмәгән булсам, сине бу вазгыятьтән коткарырлык бернинди гамәлең булмас иде!”

Шуннан елый-елый йокыдан уяндым да авызымнан чыккан шул сүзләр белән: «Әйе, Раббым, вакыты җитте. Әйе, Раббым, вакыт җиттее!!» - дип госел коенеп, иртәнге намазга мәчеткә чаптым. Аллаһка ялварып тәүбә кылырга, гөнаһларымнан арынырга, үземә җәннәт юлын сызарга теләдем. Мәчеткә кергәч колакларым белән ни ишетим, төшемдә кызым мине коткарганда әйткән аятьне укый иде хәзрәт! “Әләм йәьнилилләзинә әмәну ән тәхшәга кулубиһим ли зикриллаһ” “И иман китерүчеләр! Аллаһ зикеренә кайтыр вакытыгыз җитмәдеме?!”

Болар башыннан үткән кеше - табигыйн имамнарының олысы Малик ибне Динар хәзрәтләре. Ул кешеләр арасында төннәр буе намазлыгы өстендә елавы белән данланган зат. Ул һәрвакыт: “И Раббым! Кемнең җәннәткә, кемнең җәһәннәмгә керәсен бары Син генә беләсең! Мин боларның кайсысы?? Аллаһым, мине җәннәтлекләрдән кыл, җәһәннәмлекләрдән кылма!” - дип ялварып торган. Һәм мәчет капкасы янында басып халыкка: «И гөнаһлы бәндәләр! Раббыгызга кайтыгыз. И гасый, Аллаһка баш күтәрүче бәндәләр! Хуҗагызга кайтыгыз! И Аллаһыдан качучы бәндәләр! Раббыгызга кайтыгыз! Раббыгыз сезгә көне-төне дәшә, сезне чакыра!!» - дип мөрәҗәгать иткән.

*Безгә язалар*

## Үзгәрербезме?

*СССР таркалып дин ирегә бирелүгә 30 еллап вакыт үтте. Шушы вакыт эчендә кайсы якка нинди үзгәрешләр булды соң? Мин, авыл кешесе буларак, авыл турында язам. Бу очракта шәһәр белән авыл арасында аерма байтак. Анда намаз укучылар, мәчеткә йөрүчеләр артты. Шәһәр мәчетләрендә хиҗап бәйләп намазга, дини укуларга йөрүче хатын-кызлар күп күренә. Ә авылда дин тыелган вакытта намазга йөрмәүче карт кеше бик сирәк иде. Мәчетләр юк иде, намазны кеше өендә укыйлар иде. Дин ирегә бирелгәч, авыл саен диярлек мәчет салынды. Тик мәчеткә йөрүчеләр саны көннән-көн кими бара. Теге вакыттагы картлар үлеп бетте, ә туганда ук динсезлек чорында туган яшьләрне ышандыру җиңел түгел. Алары да бит инде хәзер 70-80 яшьлек бабайлар. Хәзерге заманда «мин дингә ышанмыйм» дигән татарны бер дә күргән юк. Ә авылда мәчеткә йөрүчеләр, күп булса, 7-8 кеше. Яшьләр вакыт юк, ди, картлар сәламәтлек юк, ди. Мәчетне үтеп китеп ашка барырга вакыт та, сәламәтлек тә табыла табылуын. Атнага бер тапкыр ярты сәгатькә җомга намазына бара алмыйлар. Корьән мәҗлесенә барып, Корьән тыңласаң - савап, бармасаң, гөнаһы юк. Мәчеткә барып намаз укысаң, зур савап, укымасаң - зур гөнаһ. Көнгә биш тапкыр намаз уку фарыз. Намаз укымаган кешегә көнгә биш тапкыр зур гөнаһ языла дигән сүз бит. Корьән мәҗлесенә дидем... Ә бит күпчелегебез ашка бара! Гадәттә, чакырганда ук: «Мин сиңа ашка әйтәм», - диләр. «Ярар, ризык булса барырмын», - дип җавап бирәләр. Чакыруы да, җавабы да ашау турында. «Мин сиңа Корьән мәҗлесенә әйтәм», - диюне бик сирәк ишетәсең. «Рәхмәт, Корьән тыңлап, Аллаһы Тәгалә сүзен ишетеп кайтырмын», - дигәнне бер дә ишеткәнем юк минем. Кешегә барып ашаган өчен генә савап булырмы икән соң? Әле чакыручысы да: «Күптән аш үткәргән юк, кешедән яхшы түгел», - дияргә мөмкин... «Намазны бер укып, кабат укымасаң, гөнаһ икән», - дигәнне дә күп ишетергә туры килә. Әйтерсең, бер дә укымасаң, гөнаһ юк... Моңа Аллаһы Тәгалә җавап бирә: «Чынлыкта без хисапҗәза өчен үлеләрне каберләреннән терге зәбез. Дөньяда аларның кылган изге һәм явыз гамәлләрен, мәчетләргә һәм изге урыннарга йөргән аяк эзләрен язып барабыз. Һәм без бөтен нәрсәне ап-ачык итеп язып, теркәп барабыз» («Ясин» сүрәсе, 12 нче аять).*

*Элек, дин тыелган вакытта, яланбаш бер хатын-кыз күрмәс идек. Ә хәзер кәнсәләргә керәсеңме, кибеткә керәсеңме, урамда да әби булган хатыннарга тиклем яланбаш. Хәтта Корьән мәҗлесләренә дә кыска җиңле, декольте күлмәк яисә чалбар киеп килүчеләр бар. Бер яктан дин ирегә, икенче яктан Европа тәэсире керде, кай урыннарда аларныкы көчлерәк тә булып чыкты. Мәчеткә йөрүчеләрнең күпчелегенең ата-анасымы, әби-бабасымы - намаз укыган кешеләр. Тик шулай да инде бүген әби-бабай булганнарның күбесе балачакта өйдә намаз укыганны күреп үсмәде шул. Менә шулар балаларына дин тәрбиясе бирә алачакмы?*

*Мөхтәрәм татарлар! Тәүбә итеп, намаз укып, ураза тотып, мөселманча яши башласак иде. Аллаһы Тәгалә «Тәүбә» сүрәсенең 27 нче аятендә әйтә: «Аллаһ тәүбә иткәннәрнең тәүбәләрен кабул итә. Аллаһ ярлыкаучы, гафу итә белүчедер».*

**Салих хәзрәт ЗИННӘТОВ,**
**Зәй районы Аксар авылы.**

# Намаз вакытлары

| Милади Август | Көн исеме | Зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррәм | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Таң беленә Чаллы | Таң беленә Казан | Мәчетләрдә укыла Уфа | Мәчетләрдә укыла Чаллы | Мәчетләрдә укыла Казан | Кояш чыга Уфа | Кояш чыга Чаллы | Кояш чыга Казан | Зәвәл Уфа | Зәвәл Чаллы | Зәвәл Казан | Өйлә Уфа | Өйлә Чаллы | Өйлә Казан | Икенде Уфа | Икенде Чаллы | Икенде Казан | Ахшам Уфа | Ахшам Чаллы | Ахшам Казан | Ястү Уфа | Ястү Чаллы | Ястү Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Пҗ | 29 | 03.24 | 01:34 | 01:47 | 03:26 | 02:04 | 02:17 | 05:26 | 03:34 | 03:47 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:45 | 17:00 | 17:14 | 21:18 | 19:37 | 19:51 | 22:48 | 21:07 | 21:21 |
| 2 | Җм | 1 | 03.26 | 01:36 | 01:49 | 03:27 | 02:06 | 02:19 | 05:27 | 03:36 | 03:49 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:44 | 16:59 | 17:12 | 21:16 | 19:35 | 19:49 | 22:46 | 21:05 | 21:19 |
| 3 | Шм | 2 | 03.27 | 01:38 | 01:51 | 03:29 | 02:08 | 02:21 | 05:29 | 03:38 | 03:51 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:42 | 16:58 | 17:11 | 21:15 | 19:33 | 19:47 | 22:45 | 21:03 | 21:17 |
| 4 | Як | 3 | 03.29 | 01:40 | 01:53 | 03:31 | 02:10 | 02:23 | 05:31 | 03:40 | 03:53 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:41 | 16:57 | 17:10 | 21:13 | 19:31 | 19:44 | 22:43 | 21:01 | 21:14 |
| 5 | Дш | 4 | 01.32 | 01:41 | 01:54 | 03:33 | 02:11 | 02:24 | 05:33 | 03:41 | 03:54 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:40 | 16:55 | 17:09 | 21:11 | 19:29 | 19:42 | 22:41 | 20:59 | 21:12 |
| 6 | Сш | 5 | 01.53 | 01:43 | 01:56 | 03:35 | 02:13 | 02:26 | 05:35 | 03:43 | 03:56 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:39 | 16:54 | 17:07 | 21:09 | 19:27 | 19:40 | 22:39 | 20:57 | 21:10 |
| 7 | Чш | 6 | 02.04 | 01:45 | 01:58 | 03:36 | 02:15 | 02:28 | 05:36 | 03:45 | 03:58 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:37 | 16:53 | 17:06 | 21:06 | 19:25 | 19:38 | 22:36 | 20:55 | 21:08 |
| 8 | Пҗ | 7 | 02.13 | 01:47 | 02:00 | 03:38 | 02:17 | 02:30 | 05:38 | 03:47 | 04:00 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:36 | 16:51 | 17:05 | 21:04 | 19:23 | 19:36 | 22:34 | 21:53 | 22:06 |
| 9 | Җм | 8 | 02.21 | 00:03 | 00:14 | 03:40 | 02:19 | 02:32 | 05:40 | 03:49 | 04:02 | 13:22 | 11:35 | 11:49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:35 | 16:50 | 17:03 | 21:02 | 19:21 | 19:34 | 22:32 | 21:48 | 22:02 |
| 10 | Шм | 9 | 02.28 | 00:16 | 00:28 | 03:42 | 02:21 | 02:34 | 05:42 | 03:51 | 04:04 | 13:22 | 11:35 | 11:48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:33 | 16:49 | 17:02 | 21:00 | 19:18 | 19:32 | 22:30 | 21:44 | 21:57 |
| 11 | Як | 10 | 02.34 | 00:26 | 00:38 | 03:44 | 02:23 | 02:36 | 05:44 | 03:53 | 04:06 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:32 | 16:47 | 17:00 | 20:58 | 19:16 | 19:29 | 22:28 | 21:39 | 21:53 |
| 12 | Дш | 11 | 02.40 | 00:35 | 00:47 | 03:46 | 02:25 | 02:38 | 05:46 | 03:55 | 04:08 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:30 | 16:46 | 16:59 | 20:56 | 19:14 | 19:27 | 22:26 | 21:35 | 21:48 |
| 13 | Сш | 12 | 02.46 | 00:42 | 00:55 | 03:47 | 02:27 | 02:40 | 05:47 | 03:57 | 04:10 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:29 | 16:44 | 16:57 | 20:54 | 19:12 | 19:25 | 22:24 | 21:31 | 21:44 |
| 14 | Чш | 13 | 02.52 | 00:49 | 01:01 | 03:49 | 02:29 | 02:42 | 05:49 | 03:59 | 04:12 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:28 | 16:43 | 16:56 | 20:51 | 19:09 | 19:23 | 22:21 | 21:27 | 21:40 |
| 15 | Пҗ | 14 | 02.56 | 00:55 | 01:08 | 03:51 | 02:31 | 02:44 | 05:51 | 04:01 | 04:14 | 13:21 | 11:34 | 11:48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:26 | 16:41 | 16:54 | 20:49 | 19:07 | 19:20 | 22:19 | 21:22 | 21:36 |
| 16 | Җм | 15 | 03.01 | 01:01 | 01:13 | 03:53 | 02:33 | 02:46 | 05:53 | 04:03 | 04:16 | 13:20 | 11:34 | 11:47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:24 | 16:39 | 16:53 | 20:47 | 19:05 | 19:18 | 22:17 | 21:18 | 21:32 |
| 17 | Шм | 16 | 03.05 | 01:06 | 01:19 | 03:55 | 02:34 | 02:47 | 05:55 | 04:04 | 04:17 | 13:20 | 11:34 | 11:47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:23 | 16:38 | 16:51 | 20:45 | 19:02 | 19:16 | 22:15 | 21:15 | 21:28 |
| 18 | Як | 17 | 03.10 | 01:12 | 01:24 | 03:57 | 02:36 | 02:49 | 05:57 | 04:06 | 04:19 | 13:20 | 11:34 | 11:47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:21 | 16:36 | 16:49 | 20:42 | 19:00 | 19:13 | 22:12 | 21:11 | 21:24 |
| 19 | Дш | 18 | 03.14 | 01:17 | 01:29 | 03:58 | 02:38 | 02:51 | 05:58 | 04:08 | 04:21 | 13:20 | 11:34 | 11:47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:20 | 16:35 | 16:48 | 20:40 | 18:58 | 19:11 | 22:10 | 21:07 | 21:20 |
| 20 | Сш | 19 | 03.18 | 01:21 | 01:34 | 04:00 | 02:40 | 02:53 | 06:00 | 04:10 | 04:23 | 13:20 | 11:33 | 11:46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:18 | 16:33 | 16:46 | 20:38 | 18:55 | 19:08 | 22:08 | 21:03 | 21:16 |
| 21 | Чш | 20 | 03.22 | 01:26 | 01:38 | 04:02 | 02:42 | 02:55 | 06:02 | 04:12 | 04:25 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:16 | 16:31 | 16:44 | 20:35 | 18:53 | 19:06 | 22:05 | 20:59 | 21:13 |
| 22 | Пҗ | 21 | 03.26 | 01:30 | 01:43 | 04:04 | 02:44 | 02:57 | 06:04 | 04:14 | 04:27 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:15 | 16:29 | 16:42 | 20:33 | 18:50 | 19:04 | 22:03 | 20:55 | 21:09 |
| 23 | Җм | 22 | 03.30 | 01:34 | 01:47 | 04:06 | 02:46 | 02:59 | 06:06 | 04:16 | 04:29 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:13 | 16:28 | 16:41 | 20:31 | 18:48 | 19:01 | 22:01 | 20:52 | 21:05 |
| 24 | Шм | 23 | 03.33 | 01:38 | 01:51 | 04:08 | 02:48 | 03:01 | 06:08 | 04:18 | 04:31 | 13:19 | 11:32 | 11:45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:11 | 16:26 | 16:39 | 20:28 | 18:45 | 18:59 | 21:58 | 20:48 | 21:01 |
| 25 | Як | 24 | 03.37 | 01:42 | 01:55 | 04:09 | 02:50 | 03:03 | 06:09 | 04:20 | 04:33 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:10 | 16:24 | 16:37 | 20:26 | 18:43 | 18:56 | 21:56 | 20:44 | 20:58 |
| 26 | Дш | 25 | 03.40 | 01:46 | 01:59 | 04:11 | 02:52 | 03:05 | 06:11 | 04:22 | 04:35 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:08 | 16:22 | 16:35 | 20:24 | 18:40 | 18:54 | 21:54 | 20:41 | 20:54 |
| 27 | Сш | 26 | 03.44 | 01:50 | 02:03 | 04:13 | 02:54 | 03:07 | 06:13 | 04:24 | 04:37 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:06 | 16:20 | 16:33 | 20:21 | 18:38 | 18:51 | 21:51 | 20:37 | 20:51 |
| 28 | Чш | 27 | 03.47 | 01:54 | 02:06 | 04:15 | 02:56 | 03:09 | 06:15 | 04:26 | 04:39 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:04 | 16:18 | 16:32 | 20:19 | 18:35 | 18:49 | 21:49 | 20:34 | 20:47 |
| 29 | Пҗ | 28 | 03.50 | 01:57 | 02:10 | 04:17 | 02:58 | 03:11 | 06:17 | 04:28 | 04:41 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:02 | 16:17 | 16:30 | 20:16 | 18:33 | 18:46 | 21:46 | 20:30 | 20:44 |
| 30 | Җм | 29 | 03.54 | 02:01 | 02:13 | 04:19 | 03:00 | 03:13 | 06:19 | 04:30 | 04:43 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:00 | 16:15 | 16:28 | 20:14 | 18:30 | 18:44 | 21:44 | 20:27 | 20:40 |
| 31 | Шм | 1 | 03.57 | 02:04 | 02:17 | 04:21 | 03:02 | 03:15 | 06:21 | 04:32 | 04:45 | 13:17 | 11:30 | 11:43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:59 | 16:13 | 16:26 | 20:11 | 18:28 | 18:41 | 21:41 | 20:23 | 20:37 |

## Балалар өчен

*Мөҗәһит ӘХМӘТҖАНОВ*



### Табышмаклар

**Көн саен мәчет ягыннан**
**Ишетелә бер тавыш.**
**Нинди моңлы чакыру ул**
**Барыбызга да таныш?** *(Азан)*

**Туксан тугыз төймәле ул,**
**Зикер әйтәсең тартып.**
**Чиста күңелдән башкарсаң,**
**Савабың торыр артып.** (Дисбе, тәсбих)

**Бизәп язылган догалар,**
**Аятьләр, изге сүзләр,**
**Өй диварларында күргәч,**
**Рәхәтләнә күзләр.** (Шамаил)

## Саулыгым – байлыгым

### Җир җиләге



Җир җиләгендә пектин, шикәр, туплау матдәләре, тимер, кальций бар. Ул лимон һәм алма кислотасына, С витаминына бай. Җиләк аппетитны, хәтерне яхшырта, су эчәсе килүне баса, ашкайнату процессын яхшырта, матдәләр алмашын, кан басымын көйли. Җиләкне кышка киптереп куйганда, тирләтү чарасы буларак кулланырга була, салкын тигәннән дә файдасы бар. Халык табиблары җиләкне гипертония, эчәклек белән проблемалар булганда булыша, диләр. Җиләкне яман шешне булдырмау максатыннан да ашарга кирәк, ди алар. Җир җиләгенең согы исә организмны зарарлы матдәләрдән чистартырга булыша. Бу җимеш составында тимер тозлары бик күп, алар кан тәнчекләре барлыкка килүне тизләтә. Тимер тозларының җитмәве азканлылыкка һәм иммунитетның көчсезләнүенә китерә. Көн саен ач карынга җир җиләге согы эчеп, еллык витамин тупларга мөмкин.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юлларга кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1150**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!
Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**12 июль 16 сәг.**
**фактта 12 июль 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**